ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

СЕНТЯБРЬ, 2018нче ел

## ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ








## Исәнме, сөекле мәктәп! Көттеңме безне? Шундый түземсезлек белән,көттек без



Менә кояшлы 1нче сентябрь иртәсе безне кабат бергә җыйды. Бүген мәктәпләрдә һәр бала көтеп алган, кызыклы вакыйгаларга бай булган яңа уку елы башлана. Күңелләрдә-сөенеч, йөзләрдә-шатлык. Җәйнең үтеп китүе бераз моңсу булса да, бүген без моңаймыйбыз. Чөнки бүген зур бәйрәм- Белем бәйрәме. 1 нче сыйныфка килүчеләр бу көнне аеруча зур түземсезлек белән көтеп алдылар. Аларны гомерләрендәге беренче кыңгырау бәйрәмнәре белән котлыйбыз! Мәктәп еллары алар өчен кызыклы, мавыктыргыч, файдалы үтсеннәр иде. Мәктәп, үзенең тарих битләренә тагын бер елын өстәп, янәдән үзенең тормышын башлап җибәрде. Барлык укучылар да, укытучылар да исән-сау җыелганнар, алга таба эшлисе дә эшлисе…

**Хәтерлим мин әле бүгенгедәй**
**Сентябрьнең 1 е җиткәнен.**
**Хәтерлим мин әле бүгенгедәй**
**Укытучы апам көткәнен.**

2017-2018 нче елда уку нәтиҗәләре буенча мәктәбебез 2 нче урынны яулады. . Быел мәктәбебездә имтиханнарны зур балларга бирдерткән ,уңышка ирешкән укытучыларыбыз байтак булды. Менә алар:
Сафиуллин Халим Салих улы,, Сөләйманова Раилә Заһит кызы, Ситдикова Клара Касыймовна, Фахреева Гөлфия Якуп кызы, Абрахманов Рәис Азат улы, Тарасова Снежанна Анатольевна һ.б

Хөрмәтле укучылар, укытучылар! Сез яраткан йорт бүген тагын сагынып сезне каршы ала. Сезне – Белем көне – Беренче кыңгырау бәйрәме белән котлыйбыз! Укучылар, белем дигән могҗизалы ил ишекләрен сезгә киң итеп ачсын. Сау-сәламәт, исән-имин булып, яңадан-яңа үрләргә ирешеп укып, укытып йөрүегезне тели ул. Бу бәйрәм, яңа уку елы күңелегездә матур хатирә булып уелсын, шатлык-куанычларга, матур белгеләргә бай булсын ул!

**Бу санда:**


| | |
|---|---|
| Белем бәйрәме | 1 |
| «Тынычлык» сыйныф сәгатьләре | 2 |
| Бу бик кызыклы | 3 |
| Мәктәп тормышы | 4 5 |
| Л.Н.Толстой безнең күңелләрдә | 6 |
| Хезмәт төбе - хөрмәт | 7 |
| Котлыйбыз | 8 |

Көзге сентябрь №1 2018

# «Тынычлык» мәктәптә беренче сыйныф сәгатьләре

Яңа 2018-2019нче уку елы башлануын хәбәр итеп яңгыраган кыңгырау укучыларны классларга дәеште. Чыгарылыш сыйныф укучылары быел беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергән 4сабыйны беренче укытучылары Гирфанова Ралия Наил кызы канаты астында үз классларына озатты. Алар:

1.Закирова Динара Ленар кызы

2. Менгазова Әминә Рөстәм кызы

3.Маняпов Ильнар Тәлгат улы

4.Халиуллин Илфат Илнур улы.

Яңа уку елының беренче тәрбия сәгате тынычлык темасына багышланды. Беслан шәһәрендә булган фаҗигале хәлләр турында укычылар таныштылар. Агымдагы елда мәктәптә 83 бала парта артына утырды. Беренче класста 3 бала укыса, тугызынчыда – 9, ә унберләр унау.Менә шулай, тагын бер уку елына аяк бастык. Сау-исән булып барчабызга да аның тәмамлануын да күрергә язсын иде .














Көзге сентябрь №1 2018


# Бу бик кызыклы!


## Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә..

Инде бу санybыз мәктәп темасына багышлангач,  бераз мәктәп турындагы кайбер мәгълүматлар белән дә танышып китик. Безнең өчен 1 сентябрь уку башланган көн булып саналса да, кайбер илләрдә ул бөтенләй башка дата. Мәсәлән, Испаниядә мәктәп бусагалары кырлардан уңыш җыелып беткәч кенә ачыла, ә Дания укучылары август урталарыннан ук укый башлыйлар икән. Ә менә Япониядә укуны бик күңелле итеп кабул итәләр һәм уку да аларда 1 апрельдә башлана. Иң борынгы уку йорты – Фес шәһәрендә урнашкан Карауин мөселман университеты икән. Бу университет б.э.к. 859 елда ачылган булган. Иң күп укучыны үзенә туплаган мәктәп Һиндстанда. Анда 28000 укучы белем ала. Иң кыйммәтле мәктәп —Халыкара яшь туташлар һәм әфәнделәр мәктәбе. Бу мәктәптә уку аена 77,5 мең доллар, ягъни 2 500 000 сум тирәсе тора. Чыгарылыш укучыларының иң зур очрашуы Алманиядә була. Анда 2 500 кеше килә. Америка яшүсмере уку өчен якынча 12 000 сәгать сарыф итсә, телевизор карауга аның 14 000 тирәсе сәгать әрәм ителә. Безнең илдә иң югары билге —”5”ле, ә иң түбәне —”1”ле саналса, Чехиядә киресенчә икән. Аларда —”1”ле алу бик сөенечле хәл. Ә инде ашханәгә килсәк, статистика буенча малайлар ашханә өчен акчаны кызларга караганда 3 тапкыр күбрәк тоталар икән. Безнең мәктәптә дә шулай түгелме икән?

## Укучылар иҗаты







# МӘКТӘП ТОРМЫШЫ.

## ФАЙДАЛЫ ОЧРАШУЛАР

7 сентябрь көне мәктәбебезгә Нурлаттан яшьүсмерләр арасында тәртипсезлек очракларын кисәтү инспекторы Чайкина Н.В. һәм Чулпан авылы участогынын янгын сүндерү җитәкчесе Тямаев Х.Х.ата – аналар белән очрашуга килгән иделәр. Алар куркынычсызлык кагыйдәләрен ата-аналарга сөйләделәр .



## Балаларны саклыйк!



Балаларның иминлеген саклау айлыгы кысаларында, 8 сентябрь көнне сыйныфларда ачык класс сәгатьләре булып узды.Укытучлар балаларга төрле экстемаль ситуацияләрдә үз-үзеңне тоту очракларын аңлаттылар, беренче ярдәм күрсәтә белергә кирәклегенә төшендерделәр.





## Спорт хәбәрләре.

18 сентябрь көнне Фома урта мәктәбендә куст фини футболы булып утте. 5 авыл Чулпан, Бикуле, Елаур, Якушка, Биләр Куле мәктәпләреннән командалар көч сынаштылар. 6 авыл арасындагы егетләрдән иң көчлеләре Фома урта мәктәбе егетләре булып чыктылар. Алар 1 урынны яуладылар.,



Көзге сентябрь №1 2018

# МӘКТӘП ТОРМЫШЫ.

15 сентябрь көнне , Нурлатта актив рәвештә Бөтенроссия күләмендә үткәрелгән “Татарстан Кроссы “ булып үтте. Аэропорт территориясенә спортны яратучы укучылыр, укытучылар, җитәкчеләр ветераннар җыелган иделәр. Матур җылы көзге һава торышы катнашучыларның күңелләрен күтәрде. Безнең мәктәптән мәктәбебез директоры Х.С.Сафиуллин һәм профсоюз председателе Р.Н.Садртдинова физик тәрбия укытучысы А.К. Замалеев 10 укучы белән катнаштылар. Гирфанов Инсаф 3 км йөгереп 1 урынны яулады һәм район грамотасы, кыйммәтле бүләк белән бүләкләнде. Афәрин Инсаф.

Аглетдинова Гөлләр.







## УҢЫШ ӨСТЕНӘ УҢЫШ.

Мәктәбебездә бик уңган,эшчән, һәрнәрсәне дә булдыра торган укучылар укый.
Яшәү чыганагы - газ!- дигән конкурста мәктәбебезнең ике укучысы катнашты. Гирфанов Инсаф инша язып республика күләмендә 3 урынны яулады. Җитәкчесе Гирфанова Ралия Наил кызы. Ә инде Хисматова Зәринә шул конкурска әкият иҗат итеп 2 урынны яулады. Җитәкчесе Аглиуллина Гөлүсә Дамир кызы. Аларны чын күңелдән котлыйбыз, алдагы елларда да шулай безне конкурслар белән шатландырып торсыннар.

Гайнуллина Алия.


## ПРОФСОЮЗ ДӘРЕСЛӘРЕ




27 сентябрдә Фома урта мәктәбендә 10-11 сыйныф укучылары өчен Профсоюз дәресләре булып үтте. Югары сыйныф укучыларына профсоюз хәрәкәте үсеше турында профсоюз председателе Садртдинова Рузилә Нурислам кызы сөйләде. Дәрес яна технологияләр, күргәзмә материаллар, уеннар, проект эшчәнлекләрен кулланып үткәрелде. Укучылар үзләренә киләчәккә бик кызыклы информацияләр тупладылар

Көзге сентябрь №1 2018

# Л.Н. ТОЛСТОЙ БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛЛӘРДӘ






Татарстан Республикасы президенты Рөстәм Миниханов 2018 елда Толстой елы дип указга кул куйды һәм игълан итте. Танылган бөек рус шагыйре, Севастополь обаронасында катнашкан, язучыга 190 яшь тулды.

10 сентябрьдә Фома урта мәктәбендә Толстойның 190 яшьлегенә багышланган класс сәгатьләре, мероприятиелар үткәрелде. Балаларның җанына үтеп керерлек хисләр калдырырлык Толстой тормышы һәм иҗаты турында презентацияләр күрсәтелде, викториналар үткәрелде, уеннар уйнатылды. “Детство” һәм “Для детей”әсәрләреннән өзекләр укылды.

10 -11 сыйныф укучылары язучы турында кызыклы мәгълүматлар сөйләделәр.

Рус теле кабинетында Толстой елына күргәзмә материаллар куелды. Күргәзмә материаллардан укучылар аның иҗаты , әсәрләре белән таныштылар. Шулай ук 10-11 сыйныф укучылары “Кем күбрәк укый, шул куп белә” дип аталган әдәби конкурс үткәрделәр. Соңыннан укучылар сорауларга җавап бирделәр. “Детектив”, “Шивровка” конкурслары үткәрделәр. Кроссвордлар чиштеләр.



Көзге сентябрь №1 2018

# Хезмәт түбе - хөрмәт.

Хезмәтнең тире ачы булса да, җимеше татлы

**Мул уңыш**
Мәктәп яны тәҗрибә участогында иртә яздан бирле эш гөрләде. Һәркемнең уртак тырышлыгы белән бик мул уңыш җыеп алуга ирештек.

Менә алтын көз җитте. Бакчада төрле- төрле яшелчәләрр өлгерде: кишере, чөгендере, бәрәңгесе һәм башка җиләк-җимеше дисеңме – барысы да. Иренмичә вакытында җыеп ал гына. Ә бәрәңгеләрне, чөгендерне, кишерне алганнан соң, кышкыга дип, без базга салабыз. Аннары бакчаны яфраклардан чистартып, казып, ашламалар сибеп калдырабыз. Икенче елга да без анда яшелчә утыртачакбыз. «Нәрсә өчен кирәк соң ул яшелчәләр?» дигән сорау туа миндә. Әлбәттә, безнең организм өчен файдалы витаминнар алар. Суган һәм шалкан салкын тиюдән саклый. Чөгендер кан өчен әйбәт. Менә шундый файдалы яшелчәләрне үзебез өчен карап, кадерләп үстерергә кирәк тә инде. Чыннан да, менә нинди ел фасылы ул көз. Бөтен муллыгы, матурлыгы белән үзенә җәлеп итә. Табигатьне сары төскә күмә, агачлардан яфраклар коела. Юкка гына көзне алтын, димиләр. Көз көне көннәр кыскара, төннәр озыная. Салкын җил исә, көннәр тиз караңгылана. Көз җиткәнен сиздереп, яңгырлар ява башлый. Кошлар, төркем-төркем булып, моңсу гына саубуллашып, җылы якларга очып китәләр. Ә шулай да көз бик матур, күңелле, мул табынлы вакыт ул.

Абдрахманова Рәзилә

Кемгә ничектер, минем үземә көз көне бакчада эшләү бик ошый. Ни өчен дигәндә, көзге муллыкны җыеп алу - нинди зур куаныч. Кишер түтәлен казып, рәтләргә салабыз да, сабакларын кисеп, чиләкләргә тутырабыз. Кайберәүләр аларны ашханә подволына кертә. Кәбестә күчәннәрен зурлар урнаштыра. Бергәләшеп җир кишәрлеген чүпләрдән арындырабыз.

Мәктәп бакчасында үскән яшелчәләрдән пешкән ашны ашау, салатлар белән сыйлану укучыларга бик ошый. Хезмәте барның ашы да бар, - дип, борынгылар бик дөрес әйткәннәр.

Таһирова Гайшә.














ХалиуллинИлфатАбдрахманов Рифат, Вәлиуллина Әнисә, Хисматова Зәринә, Никулин Тимур, Закирова Гөлинә, Ибраһимов Зөлфәт, Кәбирова Дилбәр, Хисматов Рәсим, Хайбуллина Алсу, Замалеев Алмаз

Сезгә гомернең иң озынын, бәхетнең иң зурысын, шатлыкларның иң олысын юллыйбыз. Якты ал таңнар, зәңгәр күкләр сезнең күңелеңне һәрчак яктыртсын, балкытып торсын. Таң җилләренең назлысы, җан тынычлыгы, чиксез бәхетләр, укуыгызда зурдан-зур уңышлар, яхшы күтәренке кәеф юлдаш булсын сезгә. Бөтен көчегезне укуга биреп ихлас ягымлы булып калыгыз. күңелен яуладың. Һәрвакытта да шулай шат, көләч йөзле, изге күңелле булып кал. Алга таба да шатлыкта, куанычта, бәхеттә яшәргә язсын сиңа Зур уңышлар, яхшы күтәренке кәеф юлдаш булсын сезгә. Шат, көләч йөзле, изге күңелле булып калыгыз. Алга таба да шатлыкта, куанычта, бәхеттә яшәргә язсын

Озын булсын гомерегез,

Тыныч булсын күңелегез.

Бә̆хет чишмә̆лә̆регез мул аксын,

Зур шатлыклар белә̆н таң атсын.







« К ө з г е ” Директор: Сафиуллин Хәлим Салихович «Фома урта гомуми белем мәктәбе» тарафыннан гамәлгә куелды. (423012 Нурлат районы Фома авылы Мәктәп урамы, 18) Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга. Тиражы чикләнмәгән Баш мөхәррир: Садртдинова Рузилә Нурисламовна Урынбасары: Гумерова Ләйсән Дизайнер: Заприпова Зилә Корректор: Сафиуллина Резидә Дамировна. Редколлегия: Галимов Инсаф Хисматорв Рәсим, Галиуллин Илнар, Кабирова Дилбәр, Ибрагимов өлфәт